# Мәктәп хәбәрчесе

**№6** (№19) октябрь 2020 ел

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*



**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


***/Мөхәррир сүзе /***

## *Энергетик эчемлекләрнең организмга зарары*




Соңгы вакытта кисәтүләргә, аңлатуларга карамастан, яшүсмерләр, көчләрен тәүлек буена сакларга теләүчеләр энергетик эчемлекләр эчүләре турында күп ишетергә туры килә. Чит илдә бу сыекча өлкәннәр өчен генә сатылса, бездә аңа карата чикләүләр юк. Аларны күп эчүнең нинди аянычлы нәтиҗәгә китерүе турында да еш сөйлиләр. Чыннан да, бу эчемлекнең файдасы нидә? Әллә аның зыяны күбрәкме?

Кибет киштәләрендә сатуда булган дистәләгән төрдәге энергетик эчемлекләрнең төп составы, нигездә, бер үк. Алар кешегә вакытлыча көч бирә, чөнки анда күп күләмдә кофеин салына. Реклама роликларында да бер банка "энергетик"тан көч таша, бар нәрсә үзеннән-үзе эшләнә, дип сурәтлиләр, әлбәттә. Ләкин озакка түгел, эчемлекнең тәэсире 3-4 сәгать дәвам итә, ә аннан соң организм ял таләп итә башлый. Кеше янәдән төшенкелеккә бирелә, кәефе төшә, эшләре алга бармый, тагын энергетикка үрелә...Шулай итеп, ныгып җитмәгән бала организмына тискәре йогынтысы бермә-бер арта. Нәтиҗәдә, сәламәтлеккә зур зыян салына, алкогольгә бәйлелек тә барлыкка килүе мөмкин. **ЭЧЕМЛЕКЛӘРДӘГЕ КОФЕИН ИЯЛӘШТЕРЕРГӘ, ШУЛАЙ УК НЕРВ СИСТЕМАСЫН КАКШАТА, АРУ-ТАЛУ, ДЕПРЕССИЯ, ЯРСУЧАНЛЫК, ЕШ ЙӨРӘК ТИБҮЕ ҺӘМ ЙОКЫСЫЗЛЫК**ны да иярткә сәләтле дип аңлата белгечләр. Бу эчемлек симерүгә дә китерә, бавыр һәм бөерләрнең төрле авыруларының үсешенә ярдәм итә. Бу тискәре йогынтылар галимнәр тарафыннан исбатланган. Энергетик артериаль кан басымын да күтәрә, шулай ук кандагы шикәрне арттыру куркынычы да булырга мөмкин.

Укучылар. Күргәнегезчә, сез эчәргә яраткан бу энергитикның файдасыннан зыяны күбрәк исбатланганын белә торып, эчүдән тыелырсыз диеп уйлыйбыз. Үз сәламәтлегегезне кайгыртырга чакырабыз. Сакланган кеше саулыкка туйган булыр, диләр бит.

***Мөхәррир Фәнүзә Гафиятуллина,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## *Һөнәри бәйрәмегез белән, хөрмәтле укытучылар!*




5-нче октябрьдә дөньякүләм дәрәҗәдә укытучылар көне билгеләнеп үтелә.

Укытучы. Бу сүз һәрберебезне бәхетле балачак иленә кайтара. Чөнки бу һөнәр ияләре барыбызның да тормышында зур роль уйный. Ул безне укырга, язарга, дуслар белән аралашырга, җәмгыятькә лаеклы шәхес булырга өйрәтә. Тирән белем серләренә төшендереп, олы тормышка да, һөнәр сайларга да әзерли.

Хөрмәтле апа, абыйларыбыз! Үз хезмәтегезнең дәрәҗәсен белеп, армый-талмый эшләвегез сабыйлар күңелендә беркайчан да җуелмас. Бүгенге тырышлыгыгыз Сезгә бетмәс ихтыяр көче, иҗади рух өстәсен. Укучыларыгызның рәхмәтен ишетеп, аларның уңышларына шатланып эшләргә телибез.

***Барлык укучылар исеменнән***
***газетаның редколлегия әгъзалары***



## Беренче октябрь – өлкәннәр көне!

Һәр елның 1 октябрендә дөнья җәмәгатьчелеге Халыкара өлкәннәр көнен билгеләп үтә. Бу чара олы яшьтәге кешеләрнең ихтыяҗларына һәм проблемаларына аерым игътибар бирергә кирәклеге турында сөйли. Бу чарадан, әлбәттә, без дә читтә калмыйбыз.

Бу көнне авылыбыз өлкәннәре мәдәният йорты каршына җыелды. Хезмәткәрләр аларны тулы табын әзерләп каршылады. Өлкәннәр өчен мәктәп укучылары тарафыннан тамаша күрсәтелде. Өстәл артында өлкәннәр үзләре дә җыр җырлаудан тартынмыйча, яшьлек хатирәләрен яңарттылар.

Көн кояшлы, матур, тыныч иде. Без аларга нәкъ шундый көннәр, сәламәтлек, озын гомер телибез. Беркайчан да игътибарсыз калмыйча, кадер-хөрмәттә яшәгез.

***Рузилә Хәйруллина, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары***



## Таллар буен күреп кайттык

Меңләгән төсләргә бай булган көзге табигать безне беркайчан да кызыктырмый калганы юк. Ел саен мәктәп укучылары бу көнне көтеп ала. Быелгы елны да бер матур кояшлы көндә без барыбыз да туган ягыбызның “Таллар буе” болынына юл тоттык. Балалар кайсы велосипед белән, кемдер мотоцикл белән, кечкенәләр автобуска утырып тиешле урынга бардык. Табигать безне елдагыча үзенең тынлыгы, байлыгы белән каршы алса да, калган еллардан үзгә буларак, барыбызны да кызыктырган самолет та бар иде. Ул югары кырдагы көнбагыш басуына киптергеч сыекча сибәргә килгән иде. Якыннан самолет күрмәгән балалар, бик кызыксынып аны күзәттек. Бу күренеш сәяхәтебезнең тәртипләреннән тыш иде. Без елдагыча кыр җимешләрен җыеп, компот кайнаттык. Казанда балык шулпасы пеште. Рафик абый безне учакта бәрәңге һәм кукуруз пешереп тә сыйлады.

Тамак ялгап алгач, футбол уйнап алдык. Югары сыйныфлар үзләренә тәэсир иткән көзге матурлыкларны фотога төшереп конкурс оештырдылар. Бу конкурсны мин күңел күзе конкурсы дип атар идем. Кем ничек күрә белә бит.

Без сәяхәттән ел саен бик канәгать калабыз. Алып барып күрсәткән, табигать белән хозурланырга өйрәткән укытучыларыбызга рәхмәт әйтәсебез килә.


***Әминә Туктамышева, Зөлфирә Сафиуллина, IX сыйныф укучылары***

## Җилдән җитез йөгерәбез

Инде гадәткә кергәнчә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалап, ел саен нинди дә булса массакүләм спорт чарасы үткәрелә. Быел да 10-нчы октябрь көнне “Татарстан Кроссы-2020” йөгереше булып узды. Безнең мәктәп укучылары да бу спорт чарасыннан читтә калмады. Физкультура укытучысы Олеся апа җитәкчелегендә, укучыларның күпчелеге кросста актив катнашты. Башлангыч, урта һәм өлкән сыйныфлардан иң тиз йөгерүче берәр кыз һәм малай җиңүчеләр буларак билгеләнде. Җиңүчеләр Донсков Артур (II сыйныф), Сафеева Настя (III сыйныф), Нургалиева Ләйлә (V сыйныф), Залиев Салават (VII сыйныф), Мөхәммәтова Рузилә (X сыйныф), Нурматов Халит (X сыйныф) мәктәп грамоталары белән бүләкләнделәр.



***Репортажны Виктория Нукина әзерләде***



**“Көзге имән”**

***Кәүсәр Насыйрова рәсеме, III сыйныф укучысы***



## Көзге уйланулар

Көз ! Елның бу фасылы күпме байлык, күпме муллык китерә. Табигате дә үзенчәлекле бит аның. Юкка гына алтын көз димәгәннәр бит. Бу ел фасылында урманнар да бик матур була. Агачларның матурлыгы төсләргә байлылыгы күз явын алырлык. Нинди генә төсне алсаң да, рәссам кулы булдырырлык түгел. Моны көз үзе генә булдыра ала. Урманга керсәң әкияттәге сыман.

Көз көне мине җәлеп иткән могҗиза – ул икмәк басулары. Муллык чыганагы булган басуларыбыз, инде икмәкне җыеп алганнан соң, сап-сары салам эскертләренә байый. Трактор гөрелтеләре һаман армый-талмый аны язга әзерли. Кап-кара калган басу да күзләребезгә караңгы төс булып түгел, ә ял итәргә туктаган бер мизгеле генә булып күренә. Амбарларда алтыннан да матуррак, кыйммәтлерәк булып күренгән икмәк өелә. Берсеннән-берсе мулрак уңыш биргән бакчалардан яшелчәләр җыеп алына.

Көннәр кыскара, төннәр озыная. Зәңгәр күктә җепкә тезелеп кыр үрдәкләре, торналар җылы якка китәләр. Аларны ерак юллар көтә. Туган ягы белән вакытлыча аерылырга туры килә. Аларның китүләре бераз моңсулык та уята. Аларның җыры ничектер аерылу хисен хәтерләтә.

Бу ел фасылында табигатьтә үзгәрешләр берөзлексез булып тора. Менә әле кичә генә кар явып узды. Ул бик матур иде. Һәм шунда ук эреп тә бетте. Менә шулай табигать төрле могҗизалар тудырырга сәләтле. Нинди гүзәл һәм нинди серле ел фасылы икән ул көз.

***Зөлфирә Сафиуллина, IX сыйныф укучысы***

## *Хезмәт иясе – хөрмәт иясе*

***/Күренекле шәхесләр /***



Кешене эшенә, куйган хезмәтенә карап бәялиләр. Үз һөнәренең бөтен нечкәлекләрен белгән, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер булган белгечләр зур хөрмәткә лаек. Безнең язмабызның герое – хезмәт юлы дәвамында туган мәктәбендә балаларга башлангыч белем биргән Илһамия апа Морадимова турында. Хәзерге вакытта лаеклы ялда булуына карамастан, укучыларының һәм хезмәттәшләренең күңелендә һәрвакыт сабыр, күркәм холыклы, үз эшенең чын остасы булып истә торучы Илһамия апабыз ул. Укытучылар көне уңаеннан, газетабыз репортерлары аның белән очрашып, истәлекләрен бүлеште.

**- Илһамия апа, укытучылык һөнәрен эш димиләр, ә күңел халәте диләр. Сезнең укытучы һөнәрен сайлавыгыз яшьлек хыялы идеме, әллә этәргеч бирүче булдымы?**

- Мин, иптәш кызым белән, 9-нчы сыйныфтан соң укуымны дәвам итәргә Иске Әдәм авылы мәктәбенә барырга уйлаган идем. Ул вакытта мәктәп директоры булып эшләгән Минабетдинов Гомәр абый безнең киләчәк планнар белән кызыксынды. Ул безгә мәктәптән соң Чистайга медицина училищесына барырга тәкъдим ясады. Ләкин без Тәтеш педагогия училищесына керергә дигән карарга килдек. Шулай итеп, 14 яшебездә авылдан чыгып китергә туры килде. 1980-нче елда Тәтеш шәһәрендә укуымны уңышлы тәмамлап авылга кайттым. Тагын бер күңелемдә сакланган сәбәпләрнең берсе – балачак еннары ята. Телевизор, телефон еннары юк, без хәрәкәтле еннар белән мавыктык. Шунда тегү машинасы капкачын кара такта итеп, балаларга язып “дәрес бирә” идем. Күңелем, димәк, бала чактан ук  шуңа тартылган.

**- Илһамия апа, беренче укучылар истә кала диләр?**

- Әлбәттә, барысы да исемдә. Ул балалар 1972-1973-нче  елгылар иде. Беренче укучыларымның беренче укытучылары булдым, шулай итеп.

**- Апа, әйтегез әле, бәхет  туган җирдә яшәүдәнме, әллә  яраткан хезмәттән табыламы?**

- Укып бетергән елларда  студентларны төрле шәһәрләргә юллау бар иде. Безне, иптәшем Раилә белән икебезне, мәктәп директоры булып эшләгән Сафина Лилия апа район мәгариф бүлегеннән юллама җибәрттереп, туган ягыбызга кайтарды. Комиссия тарафыннан Аксубай районына билгеләнгәч шатланганыбыз бүген дә истә. Яраткан хезмәтең, туган җирдә яшәвең белән дә бәхет икеләтә киләдер. Мин читтә яшәүне беркайчан уйламадым да, күз алдына да китерә алмыйм.

**- Сез башлангыч белем укытучысы. Шулкадәр сабырлык белән эшләгәнсез. Сабыр булуының сере нидә?**

- Миңа кайбер укытучылар югары сыйныфларны укытырга киңәш бирә иделәр. Тик шул сабыйлардан аерыласым килмәде. Сабыр булуның сере юк инде. Бары тик һәр баланы кемнеңдер яраткан сабые итеп кабул иттем. Иң беренче укучыңны яратырга, аңа шәхес иттереп карарга кирәк. Аннан соң сабырлык үрнәге булып үземнең беренче укытучым Шәрифә апа тора. Аның сабырлыгын бүген дә сокланып искә алам. Без бит бер сыйныфта 26 бала укыдык.

**- Эш барышында нинди кыенлыклар була иде?**

- Һәр чорның үзенә күрә дә авырлыгы буладыр инде. Барлык язу эшләрен дә, күрсәтмә материалларны да кулдан эшли идек. Ә башлангыч сыйныф укучысына ансыз дәрес аңлатып та булмый. Ләкин ул вакытта әти-әниләрнең мәктәпкә, укытучыга карата мөнәсәбәтләре үзгә иде.

**- Бүгенге көндә башлангыч сыйныф укучылары күп мәгълүматны кесәсендә йөрткән телефоннан ала. Аларның күп вакыт шушы кечкенә экраннарга карап вакыт сарыф итүләренә ничек карыйсыз?**

- Телефон бүгенге көннең проблемасы инде. Алар анда күп вакыт утыра. Әти-әнисе көне буе эштә булганлыктан, аларны контрольдә тоту кыен. Шуңа күрә кечкенәсенең дә, зурсының да да колагында наушник, кулында телефон. Әлбәттә, алар арасыннан да акыл ияләре дә чыгар. Ләкин күбесе еннардан ерак китә алмый. Ул аларга физик яктан да зур зыян сала, чөнки озак вакыт хәрәкәтсез утыру – яшь организм өчен тискәре йогынты ясый.

**- Илһамия апа, бүгенге укучыларга теләкләрегез нинди, ни әйтер идегез аларга?**

- Тырышып укуларын, ачык һавада уйнауларын теләр идем. Еннар бит бала күңеленең халәте. Ул ни тели – шуны уйный. Бәлки шуның белән һөнәре дә ачыкланыр иде. Китапны күп укысыннар. Алар бар да кеше тормышы өчен бәясез шөгыльләр.

**- Әңгәмәгез өчен рәхмәт Илһамия апа. Сезгә гаиләгезгә иминлек, ныклы сәламәтлек, озын гомер телибез. Укучыларыгызның рәхмәтләрен ишетеп яшәгез.**

***Әңгәмәне X сыйныф укучылары Сара Насыйрова белән Рузилә Мөхәммәтова алып барды***



# 20-нче октябрь – пешекчеләр көне!

20-нче октябрь илебездә пешекчеләр көне буларак билгеләп үтелә. Бу һөнәр ияләре булмаса, безнең укуыбыз тиешенчә бармас иде. Алар безнең өчен чын күңелдән хезмәт куялар. Илсөяр апа, Айгөл апа! Сез пешергән тәмле ризыкларны башка бер мәктәптә дә татып караганыбыз юк. Сезнең сыйлар безнең әниләребезнекенә тиң, чөнки күңел җылыгызны да кушып пешерәсез. Ашханәдә сез булганда һәрвакыт бәйрәм рухы тора.

Пешекче апалар! Сезне ихлас күңелдән һөнәри бәйрәмегез белән котлыйбыз. Ныклы сәламәтлек, гаиләгездә иминлек телибез. Безнең әйткән рәхмәтләребез Сезне гомер буе җылытып торсын.

***Барлык укучылар исеменнән газетаның редколлегия әгъзалары***

## /Котлыйбыз!/

Октябрь аенда туган көнен билгеләп үтүче башлангыч сыйныф укытучысы Камалова Сирень апаны гомер бәйрәме белән тәбрик итәбез. Гаилә бәхете, сәламәтлек, тырыш укучылар телибез.

Октябрь аенда дөньяга килгән яшь дусларыбызны туган көннәре белән котлыйбыз:

- 05.10. – Хәбибрахманова Хәнифә (IV с-ф);
- 09.10. – Нургалиева Ләйлә (V с-ф);
- 11.10. – Закиров Инсаф (бакча төркеме);
- 17.10. – Галиәскәрова Айшә (бакча төркеме);
- 22.10. – Хафизов Илфат (бакча төркеме),
- 21.10.-Хөснуллина Кмилә ( VIII-с-ф)
- 22.10. – Нурматов Халит (X с-ф);
- 24.10. – Хәйруллин Данил (VIII с-ф);
- 25.10. – Галимов Риаз (VIII с-ф);
- 29.10. – Хәбибрахманов Әхмәт (VIII с-ф);




Аларга ныклы сәламәтлек, укуларында уңышлар теләп калабыз.

## /Безнең уңышлар/

Балаларның һәр яклап үсүен тәэмин итү өчен төрле ярышлар, конкурслар даими уздырылып тора. Республика уздырган “Язу серләре” конкурсында бакча төркемендә йөргән балалардан Сафиуллина Гөлсем, “Эрудит” конкурсында Закиров Инсаф белән беренче сыйныф укучысы Нурматова Асия катнашып, I урыннарны алуга ирештеләр. Яшь дусларыбызны беренче җиңүләре белән тәбрик итәбез. Алдагы еллар аларга тагын да зуррак җиңүләр китерсен.

## Авылларыбыз тарихыннан

## /ТАССРның 100 еллыгына/

Иске Әдәм авылы Аксубай районы җирлегендәге йомышлы (чирүле) татар авыллларының иң борынгысы. Ул 1649-нчы елгы “Писцовая книга” дип аталган документта ук телгә алына. Бу авылга чирүле татарлар бернчә дулкын булып килеп төпләнәләр. Иң беренчеләрдән булып, Алатыр морзасы Дусәй князь Булаев, Алексей Михайлович патшалык иткән дәвердә (1645-1675-нче еллар арасында ) хәрби хезмәтләре өчен Әдәм авылыннан җирләр ала. Дусәй морзаның 1670-нче елның көзендә С.Разин фетнәсе вакытында баш күтәрүчеләр ягында хөкүмәт гаскәрләренә каршы сугышканлыгы билгеле. Патшага каршы сугышкан кешегә җирләр бирелү әлбәттә шикле. Шунлыктан Дусәй морзаның Әдәм авылыннан өлеш алуы 1670-нче елга кадәр булгандыр диергә нигез бар.

Йомышлы татарларның икенче дулкыны Әдәм авылына 1700-нче елда килә. Чыгышлары белән шул ук Алатыр өязеннән булган Сөләйман Сөенбаев үзенең 15 иптәше белән Суыксу (хәзер Әлки районында) авылыннан Әдәмсуына күченеп килеп җирләр алалар.

1712-нче еллар тирәсендә Әдәмсуы авылыннан бер төркем халык аерылып чыгып, Яңа Әдәм авылына нигез салалар. Бу вакыйгага кадәр Әдәмсуы безнең тирә-якта гына түгел, бөтен Кама арьягы авыллары арасында иң зурларыннан саналган.

1745-нче елда Иске Әдәм авылында 216 ир-ат теркәлгән. Аларның 10 нан артыгы 1720-1745-нче еллар арасында төрле авыллардан күчерелгән лашманчылар. Боларны инде күченеп килүчеләрнең чираттагы өченче дулкыны дип әйтсәк була. Шул ук елны Яңа Әдәм авылында 109 ир-ат яшәгәнлеге язылган.

1748-1762-нче еллар арасында Иске Әдәмнән 22 йорт аерылып чыгып, Такталы авылына нигез салалар. 1782-нче елда Иске Әдәмдә 94 йомышлы, 20 чукындырылган татар, Яңа Әдәмдә 101 йомышлы , 6 чукындырылган татар, Так-талда 117 йомышлы, 8 чукындырылган татар язылган ( ир-атлар саны ).

Авылның “Әдәмсуы” дигән исеме елга атамасыннан алынган. Шул авылдан чыккан ветеран укытучы Мөнирә апа Фәтхетдинова язып алган риваять буенча елгага “Әдәм суы” дигән исеме, суы кеше эчәргә яраклы, саф, чиста бул-ганлыктан кушылган дип аңлатыла.

Әдәмсуы елгасы буенда урнашкан Шомыртлы, Емелькино (Салмай) Яңа Чуаш Әдәмсуы авыллары 1782-1795-нче еллар арасында барлыкка килгәннәр. Иске Чуаш Әдәм суы борынгырак авыл. Ул 1699-нчы елда ук телгә алына. Бу авылларның бер-берсенә тугандаш икәнлеген межа чикләренең уртак булуы раслый.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Сара Насыйрова, Виктория Нукина, Рузилә Мөхәмматова, Зөлфирә Сафиуллина